**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАВАЛ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422727, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Кавал авылы, Мәктәп ур, 3

**СОВЕТ БОЛЬШЕКОВАЛИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Олы Кавал, Мәктәп ур., 3

Тел./факс: +7(84365) 60-0-38, e-mail: Bkoval.Vsg@tatar.ru


**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**5 август 2019 ел** **№ 116**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге тарафыннан шәһәр төзелеше өлкәсендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында**

Биектау муниципаль районы Советының “Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү һәм раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләрне раслау турында”, 2019 елның 30 маендагы 300 номерлы карарын караганнан соң, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, “Олы Кавал авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 ст. 3 һәм 4 бүлекләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру өлешендә вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итәргә.

Кабул ителә торган вәкаләтләрнең тормышка ашыру предметы булып торалар:

- җирлекнең генераль планын раслау;
- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау;
- җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектлавының җирле нормативларын раслау.

2. Олы Кавал авыл җирлеге Башкарма комитетына Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру буенча килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Олы Кавал авыл җирлеге Башлыгына имза куюга тапшырырга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
авыл җирлеге башлагы урынбасары Х.Г.Забиров